КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 3 ноябрь г.Казань № б-2231

Дәүләт идарәсендә платформа модельләрен гамәлгә кертү, шулай ук вазыйфаи затларның цифрлы нигездә үстерү проектлары эшен оештыру мәсьәләләрендә компетенцияләрен арттыруны тәэмин итү максатларында:

1. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең җавап бирә торган тармакта мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү буенча проектларны тормышка ашыру өчен җаваплы урынбасарлары компетенцияләре паспортын;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары карамагындагы бюджет оешмаларының оешма эшчәнлеген мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү буенча проектларны тормышка ашыру өчен җаваплы җитәкчеләре компетенцияләре паспортын.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы оешмаларга бу боерык белән расланган компетенцияләр паспортларына таянып эш итәргә, шул исәптән җавап бирә торган тармакта мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү буенча проектларны тормышка ашыру өчен җаваплы затларның вазыйфаи регламентларына тиешле компетенцияләрне кертүне тәэмин итәргә, шулай ук аларны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләре урынбасарларының вазыйфаи регламентларына җавап бирә торган эшчәнлек

тармагында цифрлы трансформацияләү өлкәсенә караган компетенцияләрне кертү өлешендә үзгәрешләр кертергә, шулай ук аны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 3 ноябрь, б-2231 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары карамагындагы бюджет оешмаларының оешма эшчәнлеген мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү буенча проектларны тормышка ашыру өчен җаваплы җитәкчеләре компетенцияләре
паспорты

Цифрлы нигездә үстерү өлкәсендә һөнәри компетенцияләр – мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү өлкәсендә процесслар, проектлар, продуктлар белән идарә итү ысулларын һәм инструментларын функциональ куллануга һәм кирәкле һөнәри бурычларны даими хәл итүгә бәйле компетенцияләр төркеме.

Бу Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары карамагындагы бюджет оешмаларының оешма эшчәнлеген мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү буенча проектларны тормышка ашыру өчен җаваплы җитәкчеләре компетенцияләре паспорты Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә проектлар җитәкчесе» һөнәри стандартын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 893н номерлы боерыгы нигезендә эшләнде.

Бюджет оешмалары җитәкчеләренең һөнәри компетенцияләре дәрәҗәсенә карата таләпләр – мәгълүматлаштыру һәм идарә итү процессларын һәм технологик процессларны цифрлы трансформацияләү өлкәсендә системалы бурычларны хәл итүдә белемнәр, осталыклар һәм күнекмәләр булу, аларны реинжиниринглау концепциясен һәм технологиясен билгеләү, мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү процессларында катнашкан персонал өчен нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләрен билгеләү.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары карамагындагы бюджет оешмаларының оешма эшчәнлеген мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү буенча проектларны тормышка ашыру өчен җаваплы җитәкчеләре компетенцияләре
таблицасы

| Компетенция исеме | Компетенция тасвирнамәсе | Компетенция тасвирнамәсенең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Цифрлы нигездә үстерү белән идарә итү | 1. Цифрлы нигездә үстерү белән идарә итүдә страте- | 1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкар- |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | гик менеджмент инструментлары, ысуллары.<br>2. Илкүләм максатларын, илкүләм проектларын (программаларын) һәм дәүләт программаларын, төбәк проектларын җайга сала торган норматив хокукый актлар.<br>3. «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, цифрлы трансформацияләү буенча муниципаль һәм тармак программалары.<br>4. Цифрлы икътисад нигезләре.<br>5. Мәгълүматлар базаларын, мәгълүмат технологияләрен һәм мәгълүмат системаларын эшләүгә һәм эксплуатацияләүгә төп алымнар.<br>6. Республикада цифрлы трансформацияләү үсешенең төп трендлары, заманча цифрлы технологияләр һәм цифрлы платформалар. ИТ-өлкәдә төп республика һәм җәлеп итеlә торган субъектларның роле.<br>7. ИТ-технологияләрне кулланып, дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәткәндә мәгълүматны үзгәртү алгоритмнары.<br>8. Цифрлы һәм электрон технологияләр нигезендә эшли торган дәүләт (муниципаль) идарәсе систе- | ма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары карамагындагы бюджет оешмалары эшчәнлегендә мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү нәтиҗәлелеген бәяләүнең балансланган күрсәткечләре системасын проектлау ысуллары, аларны оешма бүлекчәләре нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләренә декомпозицияләү.<br>2. Дәүләт (муниципаль) идарәсе системасы кысаларында күрсәткечләр системасын мониторинглау ысуллары һәм технологияләре.<br>3. Аналитик мәгълүмат һәм статистик хисаплылык җыю ысуллары.<br>4. Мәгълүматны саклау ысуллары.<br>5. Цифрлы дәүләт (муниципаль) идарәсе технологияләре.<br>6. Мәгълүматлаштыру процессларын модернизацияләү һәм оешма эшчәнлеген цифрлы трансформацияләү буенча тәкъдимнәр әзерләү технологияләре.<br>7. Оешмада һәм аннан читтә проектларны презентацияләү һәм яклау технологияләре.<br>8. Мәгълүматлаштыру, цифрлы трансформацияләү программаларын һәм стратегияләрен һәм аларны тормышка ашыру буенча |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | масын аңлау.<br>9. Халыкара һәм Россия законнарын; «Дәүләт платформа буларак» концепциясен аңлау | «юл картасын» эшләү технологияләре.<br>9. Мәгълүмат системаларын һәм ИТ-продуктларын проектлауны һәм эксплуатацияләүне җайга сала торган Россия һәм халыкара стандартларны һәм норматив документларны, шулай ук, аларны файдаланып, идарә итү регламентларын куллану технологияләре |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 3 ноябрь, б-2231 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары
һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә
органнары җитәкчеләренең җавап бирә торган тармакта мәгълүматлаштыру
һәм цифрлы трансформацияләү проектларын тормышка ашыру өчен
җаваплы урынбасарлары компетенцияләре
паспорты

Цифрлы нигездә үстерү өлкәсендә һөнәри компетенцияләр – мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү өлкәсендә процесслар, проектлар, продуктлар белән идарә итү ысулларын һәм инструментларын функциональ куллануга һәм кирәкле һөнәри бурычларны даими хәл итүгә бәйле компетенцияләр төркеме.

Бу Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең җавап бирә торган тармакта мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү буенча проектларны тормышка ашыру өчен җаваплы урынбасарлары компетенцияләре паспорты Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә проектлар җитәкчесе» һөнәри стандартын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 893н номерлы боерыгы нигезендә эшләнде.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләре урынбасарларының һөнәри компетенцияләре дәрәҗәсенә карата таләпләр – мәгълүматлаштыру, идарә итү процесслары һәм технологик процессларны цифрлы трансформацияләү өлкәсендә системалы бурычларны хәл итүдә белемнәр, осталыклар һәм күнекмәләр булу, аларны реинжинирингләу концепциясен һәм технологиясен билгеләү, мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү процессларында катнашкан персонал өчен нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләрен билгеләү.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан
Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары
җитәкчеләренең җавап бирә торган тармакта мәгълүматлаштыру һәм цифрлы
трансформацияләү буенча проектларны тормышка ашыру өчен җаваплы
урынбасарлары компетенцияләре
таблицасы

| Компетенция исеме | Компетенция тасвирнамәсе | Компетенция тасвирнамәсенең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Цифрлы нигездә үстерү белән идарә итү | 1. Цифрлы нигездә үстерү белән идарә итүдә стра- | 1. Җавап бирә торган тармакта цифрлы трансформа- |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | тегик менеджмент инструментлары, ысуллары.<br>2. Илкүләм максатларын, илкүләм проектларын (программаларын) һәм дәүләт программаларын, төбәк проектларын җайга сала торган норматив хокукый актлар.<br>3. «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, цифрлы трансформацияләү буенча муниципаль һәм тармак программалары.<br>4. Цифрлы икътисад нигезләре.<br>5. Мәгълүматлар базаларын, мәгълүмат технологияләрен һәм мәгълүмат системаларын эшләүгә һәм эксплуатацияләүгә төп алымнар.<br>6. Республикада цифрлы трансформацияләү үсешенең төп трендлары, заманча цифрлы технологияләр һәм цифрлы платформалар. ИТ-өлкәдә төп республика һәм җәлеп итеЛә торган субъектларның роле.<br>7. ИТ-технологияләрне кулланып, дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәткәндә мәгълүматны үзгәртү алгоритмнары.<br>8. Цифрлы һәм электрон технологияләр нигезендә эшли торган дәүләт (муни- | цияләү нәтиҗәлелеген бәяләүнең балансланган күрсәткечләре системасын проектлау ысуллары, аларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары бүлекчәләре нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләренә декомпозицияләү.<br>2. Җавап бирә торган тармакта хуҗалык итүче субъектлар эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү макрокүрсәткечләрен декомпозицияләү ысуллары.<br>3. Дәүләт (муниципаль) идарәсе системасы кысаларында күрсәткечләр системасын мониторинглау ысуллары һәм технологияләре.<br>4. Аналитик мәгълүмат һәм статистик хисаплылык җыю ысуллары.<br>5. Мәгълүматны саклау ысуллары.<br>6. Цифрлы дәүләт (муниципаль) идарәсе технологияләре.<br>7. Җавап бирә торган эшчәнлек тармагында мәгълүматлаштыру һәм цифрлы трансформацияләү процессларын модернизацияләү буенча тәкъдимнәр әзерләү технологияләре.<br>8. Проектларны презентацияләү һәм яклау технологияләре. |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | ципаль) идарәсе системасын аңлау.<br>9. Халыкара һәм Россия законнарын; «Дәүләт платформа буларак» концепциясен аңлау | 9. Мәгълүматлаштыру, цифрлы трансформацияләү программаларын һәм стратегияләрен һәм аларны тормышка ашыру буенча «юл картасын» эшләү технологияләре.<br>10. Мәгълүмат системаларын һәм ИТ-продуктларын проектлауны һәм эксплуатацияләүне җайга сала торган Россия һәм халыкара стандартларны һәм норматив документларны, шулай ук, аларны файдаланып, идарә итү регламентларын куллану технологияләре |